# Нәсыйхәт

җомга
25
ноябрь
2011 №10

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


## Яңалыклар

### УНИКАЛЬ КОРЪӘН

17 ноябрь көнне Казанда Кол Шәриф мәчетендә дөньядагы иң зур Коръәнне тәкъдим итү тантанасы булды. Чарада Мамадыш мөхтәсибе һәм мәдрәсә җитәкчелеге дә катнашты. Изге китап үзенең зурлыгы белән генә түгел, матурлыгы, күркәмлеге белән таң калдырды. Ул Гиннес рекордлар китабына кертелгән.

### БЕРГӘЛӘП ИЗГЕЛЕК КЫЛЫЙК

Инвалидлар көне уңаеннан агымдагы елның 1нче декабреннән 10нчы декабренә кадәр «Изгелекләр кылырга ашыгыгыз» исемле декада оештырыла. Мәдрәсәдә бу чара җәмәгатьчелекне физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр проблемасына җәлеп итү, гарипләр хәзерге заман җәмгыятендә яшәргә сәләтле түгел, дигән фикерне юкка чыгару максатыннан үтә. Матди һәм рухи ярдәм бирергә теләүчеләр өчен телефон: 89172802391

### "ИҢ ЯХШЫ ШӘКЕРТ" БӘЙГЕСЕ

20 нче декабрьдән Мамадыш мәдрәсәсе "Иң яхшы шәкерт" бәйгесе игълан итә. Әлеге бәйгенең максаты: дини гыйлем бирүне көчәйтү, популярлаштыру, студентларның белем сыйфатын яхшырту, укытучыларның белгечлек дәрәҗәсен арттыру, студентларны төрле иҗтимагый чараларда катнашуга кызыктыру. Бәйгенең нәтиҗәләре һәр ай азагында билгеләнеп торачак. Җиңүчеләрне бүләкләр көтә.

### СТИПЕНДИЯ БИЛГЕЛӘНДЕ

1 нче декабрьдән Мамадыш мәдрәсәсе яхшы укучы шәкертләргә стипендия билгеләде. Укуларында яхшы нәтиҗәгә ирешкән студентлар һәр ай саен акчалата стипендия алачак һәм бүләкләр белән бүләкләнәчәк.

### КАЛӘМНӘРЕГЕЗНЕ ЧАРЛАГЫЗ!

Мамадыш мәдрәсәсе "Иң яхшы дини мәкалә" дигән бәйге игълан итә. Ул 21 нче ноябрьдән алып 30 нчы декабрьга кадәр дәвам итәчәк. Мәкаләләрнең яхшы дип табылганнары "Нәсыйхәт" гәҗитендә бастырылачак. Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә.

### ЮМАРТНЫҢ МАЛЫНА БӘРӘКӘТ ИҢӘР

Ай бышында мәдрәсә тарафыннан елда үткәрелеп килә торган "Гошер" бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. Бу чара Мамадыш шәһәре мәхәлләләре һәм район авыллары арасында үтте. Бәйге ике номинациядә үткәрелде. Олы һәм кечкенә авылларга аерым урыннар билгеләнде. Зур авыллардан беренче урынны Катмыш, икенче урынны Югары Сон, өченче урынны Кече Сон мәхәлләләре яулады. Кечкенә авыллардан беренче урынга Арташ, икенче урынга Норма, өченче урынга Акман авыллары лаек булдылар. Аларга грамоталар һәм бүләкләр тапшырылды. Мәдрәсә җитәкчелеге һәм шәкертләр аларга үз чиратында зур рәхмәтләрен белдерделәр.

### КОРБАННЫ ИНВАЛИДЛАРГА

Хәйрия акциясе кысаларында Мамадыш мәдрәсәсе инвалидларга ярдәм итү оештырды. Аларга корбан ите таратылды. Ярдәмгә мохтаҗ булганнар чарадан канәгать калдылар, рәхмәтләрен белдерделәр.

## Мәдрәсәбездә Корбан гаете



**Мөселманнарның иң зур һәм мөбарәк бәйрәмнәренең берсе–Корбан гаете. Корбан чалу Аллаһы Тәгалә тарафыннан Аңа ел буена биргән нигъмәтләренә шөкер итәр өчен әмер ителгән.**

.....................................
**ФИРАЯ МИНГАЛИЕВА**

Шушы бәйрәм уңаеннан, 7нче ноябрь көнне шәһәребез мәдрәсәсендә беренче тапкыр зурлап Корбан бәйрәме үткәрелде. Уку йорты эчендә бәйрәм сәгать унбердә башланды. Анда әбиләр, бабайлар, апалар, абыйлар, балалар бик күп иде. Мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин аны "Фатиха" сүрәсе белән ачып җибәрде. Ул көчле тавышы, мәкам белән сүрәне көйләгәндә аның һәрбер сүзен йөрәгем аша уздырдым. "Бар бит гыйлемле хәзрәтләребез, Аллага шөкер!",–дип уйладым. Районыбыз мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миннегалиев: "Кешеләр алдында дәрәҗәбез булсын, үзебезнең хезмәт сөючәнлегебез, чисталыгыбыз, пакьлегебез, намусыбыз, тырышлыгыбыз белән үрнәк булып торыйк. Дөньялык өчен генә түгел, ахирәтебез өчен дә гамәлләребез булсын. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршына үзебез белән алып бара торган намазларыбыз, уразаларыбыз, зәкәтләребез, корбаннарыбыз да булсын",–диде. Район башкарма комитеты җитәкчесе Илнар Хафизов, аның социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Алена Смирнова барча мөселман халкын бәйрәм белән котладылар. Бәйрәмдә Сабирҗан Әхмәтҗанов, Мансур хәзрәт Батыров, Әхмәт Ясәви мәчетеннән Рәсимә абыстай Гайнетдинова мөнәҗәт җырладылар. Илһам хәзрәт, шагыйрь Рафаил Газизов шигырьләрен укыдылар. Иң кызыгы мәдрәсәдә алган белемнәрне тикшерү булды. Анда кечкенә балаларның күп белүләренә шаккатып утырдым. Хәзрәтләребез, абыстайлар биргән белемнәр җилгә очмаганына сөендем. Әхмәт Ясәви мәчетеннән кечкенә Алмаз Хәкимуллин намаз уку турында шигырьләр сөйләде. Бәйрәм чәй табыны артында дәвам итте. Корбан итеннән пылау, аш ашадык. Тәүге мәртәбә генә үткәрелсә дә, бәйрәм төерсез үтте. Бу бөек бәйрәмнең эчтәлеге нәкъ менә кешеләр мәнфәгатен кайгырту, аларны ярату һәм ярдәм кулы сузуга нигезләнгән. Изге Корбан бәйрәме көнендә кылган догаларыбыз кабул булсын, изге ниятләребез һәм якты хыялларыбыз тормышка ашсын. Йортларыбызга, мәдрәсәбезгә бәрәкәт, күңелләребезгә–иман нуры, бу бәйрәмне оештырган абыстайларыбызга, хәзрәтләребезгә иминлек, тынычлык һәм мәхәббәт хисләре иңсен. Тәкәбберлекне ташлап, ата-анага, туганнарга һәм бөтен җан ияләренә ихтирамлы булып, бәхиллекләрен сорап, хәердогаларын алырга тырышырга кирәк. Барыбыз да изгелек эшләргә ашыгыйк!

# ДӨНЬЯ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

**БАШКОРТСТАННЫҢ МӘКТӘП ҺӘМ БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫНДА ХӘЛӘЛ РИЗЫК БУЛАЧАК**

Мондый тәкъдим «Ихлас» мәчетендә узган «түгәрәк өстәл» вакытында яңгыраган иде. «Түгәрәк өстәл»дә катнашучылар балаларны хәләл азык белән туклandыру мәсьәләсен күтәрде. Нигездә, бу тәкъдимне «Хәләл» стандарты комитетының эксперт группасы җитәкчесе Рәҗәб Мөхәммәдиев ясады. Башкортстанның Сәүдәсәнәгать палатасы вице-президенты Азат Фазлыев һәм Башкортстан Илбашы каршындагы дәүләт-конфессияара мөнәсәбәтләр Советы киңәшчесе Илюс Әхәтов та балалар бакчасына хәләл ризык кертү ягында булды. Һәм Башкортстан хөкүмәтенә әлеге тәкъдимне әйтәчәкләрен белдерде, дип хәбәр итә islam-portal.ru.

**РИУ БЕЛӘН ӘЛМӘТ ҺӘМ ТҮБӘН КАМА МӘДРӘСӘЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮЕ ТУРЫНДАГА КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ**

Рәсәй ислам университетының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, РИУда университет белән Әлмәт һәм Түбән Кама мәдрәсәләренең бергә эшләвенә нигезләнгән килешүгә кул куелды. Килешүгә ирешү кысаларында РИУ мәдрәсәгә методологик эшендә актив ярдәм итеп торачак. Түбән Кама РИУ студентларын үзенә практикага алачак, Ә РИУ мәдрәсә укытучыларын һәм шәкертләрен чараларга, университетта үтүче семинар, белем бирү курслары, бәйгеләргә җәлеп итәчәк.

**“ТАТАРСТАН ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНЕҢ ИҢ ЯХШЫ ДИНИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАСЫ” ДИГӘН I РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕ СТАРТ АЛДЫ**

Бәйге 2011-2012 уку елында үтәчәк. Оештыручылары Татарстан Диния нәзарәте. Әлге бәйгенең максаты: дини гыйлем бирүне кочәйтү, популярлаштыру, студентларның белем сыйфатын яхшырту, укытучыларның белгечлек дәрәҗәсен арттыру, студентларны төрле иҗтимагый чараларда катнашуга кызыктыру. Бәйге барышында мәдрәсә, китапханә, тулай торакның халәте, укытучылар составы (фәнни дәрәҗә, укыту стажы, публикацияләр); студентларның төрле чаралардагы активлыгы (олимпиада, спартакиада, иҗтимагый чаралар) бәяләнәчәк. Бәйгенең нәтиҗәләре уку елы азагында билгеле булачак. Өстәмә мәгълүмат нәзарәт сайтының (http://dumrt.ru/documents) ДОКУМЕНТЫ бүлегендә.

**КАЗАНДА “ЭКСТРЕМИЗМГА КАРШЫ МӘДӘНИЯТЛӘР ДИАЛОГЫ” ДИГӘН ТЕМАГА “ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ” УЗАЧАК**

29 ноябрь Татарстан башкаласында «Экстремизмга каршы мәдәниятләр диалогы» дигән темага «түгәрәк өстәл» үтәчәк. Аны Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты белән берлектә Татарстан җөмһүриятенең Фән һәм белем бирү министрлыгы оештыра. Чараның максаты — студентлар аудиториясен экстремизм проблемаларына җәлеп итү һәм яшьләрнең дөньяга карашларында толерантлык формалаштыру.

**ТАТАРСТАННЫҢ МИЛЛИ МУЗЕЕ ФИЗИК КИМЧЕЛЕКЛЕЛӘРӨЧЕН“ИЗГЕЛЕКЛӘР КЫЛЫРГА АШЫГЫГЫЗ” ДИП ИСЕМЛӘНГӘН ДЕКАДА ҮТКӘРӘ**

Агымдагы елның 1нче декабреннән 10нчы декабренә кадәр «Изгелекләр кылырга ашыгыгыз» исемле декада үтәчәк. Музейда күпсанлы хәйрия чаралары үтү белән берргәттән, әлегесе Халыкара физик кимчелеклеләр көненә багышланган була. Музейга килүче кимчелеклеләр музей экспозицияләрен, күргәзмәләрен карый, экскурсия үтә алачак. Алар өчен махсус музей шөгыльләре, очрашулар булачак, дип хәбәр итә Татарстанның мәдәният министрлыгы.

2012 елның язында глобаль мөселман социаль челтәр сайты ачылачак

SalamWorld глобаль мөселман социаль челтәр сайтының ачылачагын 2012 елның язына планлаштыралар. Моның хакында Мәскәүдә узган VII Мөселман форумында билгеле булды. Хезмәттәшлек итү турындагы Килешүгә SalamWorldның баш мөхәррире, Коръәнне тәрҗемә иткән, философия фәннәре докторы Эльмир Кулиев һәм СМР рәисе, мөфти шәех Равил Гайнетдин кул куйды. SalamWorld–ул халыкара проект. Аның уйлап табучылары Төркия, Казахстан, Германия, Мисыр, Рәсәй һәм башка илләрнең мөселманнары.

**tatar-islam.ru сайты кулланылды**

# Икмәк кадере

**Август ае башлануга ашлык кабул итү урыннарына машина–машина ашлыклар көн-төн килеп, ашлык белән бергә безнең күңелләргә шатлык та китерә.**

РӘЙСӘ РӘХИМҖАНОВА

Арыш-бодайдан бит безнең төп азыгыбыз–ипи-ипекәй пешерелә. Икмәксез көндәлек аш та, бәйрәм табыны да узмый–ул бик күркәм азык. Элек-электән бездә балаларны бик кече яшьтән үк ипинең кадерен белергә, валчыгын да төшермичә ашарга өйрәткәннәр. Ипине гаиләдә иң өлкән кеше кисеп, иң олы аш итеп табын уртасына куйганнар, аяк өсте ашап йөрергә кушмаганнар. Сугыш вакыты һәм сугыштан соңгы авыр елларны минем һич онытасым юк... Бервакыт бригадир абый кереп, әнкәйгә тегермән буасында эшләүчеләргә ашарга пешерергә кушты: Сездән кулай кеше юк, өегез дә зур, эшләүчеләргә дә якын дигәч, чамалап кына бирелгән оннан ипи пешерәбез, аның хуш исе бөтен урамга тарала. Фермага эшкә баручы апалар: “Гайниамал апа, ач әле тәрәзәңне бер рәхәтләнеп исник, исен иснәсәк тә ашагандай булабыз”,–диләр иде. Ул вакытта ипине мич төбен себереп кирпеч өстендә, ә ашны инеш буенда зур казанда инеш суына тоз салып он болгатып пешерә идек, башка нәрсәсе юк иде. 1952 нче елларда да әле ипигә зур-зур чиратлар булды. Алабуга шәһәрендә укыганда, кышкы каникулга кайтыр алдыннан, иркенрәк вакытка очрасак, бәрәр атна алдан күчтәнәчкә ак ипи алып куя идек. Ул искергән ипине әнкәйләр бик оста итеп яңартып, зур күчтәнәч итеп чәй эчә идек.

Хәзер без кунакта яшибез, өстәл өстебез–оҗмах нигъмәтләре. Аллаһыга мең шөкер. Ипекәйнең нинди генә сортлары юк, бернинди чират юк, әле сайланабыз. Кызганычка каршы аның кадерен белмәүчеләр дә очрый. Ходай Тәгалә, шундыйларга сабак булсын дип, узган ел корылык белән дә кисәтеп куйды. Гомер булмаганны бакчада бәрәңгеләр булмады, болын -кырларда үләннәр саргаеп кипте. Әле дә җир анабыз ничек түзә, халык азды бит: ата улны, ана кызны белми, нинди генә вәхшилек кылмыйлар. Әле дә Раббыбыз ярдәменнән ташламады. Хөкүмәт бәрәңгесен, печән –саламын, фуражын өләште, пенсиясен биреп барды. Ә без хатаны үзебездән эзләмибез, аны төзәтәсе урынга кемнәрнедер гаеплибез, имеш, печәннең сыйфаты юк, бәрәңге тәмле түгел, орлыкка дигәне уңамы, юкмы, тикшерелмәгән. Инде узганнар узганда калсын, алда хәерле еллар килеп, бер-беребезгә мәрхәмәтле булып, бер-беребезне ихтирам итеп, бу тормышыбызга Аллаһы Тәгаләгә шөкеранә итеп яшәсәк иде. Аллаһы Тәгалә ипекәйләрдән аермасын.

# МӨСЕЛМАН ТАТАР КЫЗЫ: исеме һәм җисеме

**Әбиләребез әйтүенчә, илленче елларга кадәр татар хатыннары чәчләрен туздырып, урам буйлап яланбаш бөтенләй йөрмәгәннәр. Безгә кадәр тормыш иткән әнкәйләребездән алырлык үрнәкләр дә бик күп.**

Алар өйгә чит ирләр керсә, яулык кыры белән йөзен каплап, эчке бүлмәгә кереп китә торган булганнар, егерме ел килен булып торып, иренең атасыннан тел яшергәннәр. Шул тыйнак, гыйффәтле аналарның батыр, кыю йөрәкләренә карасаң да, таң каласың. Ирләре сугышка киткәч, алар көн-төн эшләү өстенә, җидешәр-сигезәр бала да тәрбияли алганнар. Тормыш сынаулары аларның нәзек күңелләрен сындыра алмаган. Бүген исә, кыйммәтләрнең асты-өскә килгән мәлдә, бу әйберләрне ишетү безнең өчен сәер булып тоела.

Әйе, мөслимәләр ничек итеп киенеп йөрергә тиешлеген бик яхшы белә. Аллаһ хатын-кыз затын аеруча зирәк, күркәм кыяфәттә бар итте. Ләкин хатын-кызның ул зиннәте һәр күз өчен хәләл булмады. Шәригать хатын-кызга чәчләрен яшерергә, муеннарын, күкрәк тирәләрен каплап йөрергә куша. Бөркәнчек турында без Коръәни -Кәримдә: «Әй Пәйгамбәр, үз хатыннарыңа вә кызларыңа әйт, әгәр бер эш белән урамга чыксалар, бөркәнчекләрен башларына салсыннар, ягъни барча әгъзаларын каплый торган зур бер әйбер белән төренеп чыксыннар. Шулай төренеп чыгулары аларның хөр вә мөэминә хатын икәнлекләрен белергә якынрак була» (Әхзаб, 59) дигән юлларны укыйбыз. Күргәнебезчә, Ислам хатын-кызга бөек хөрмәт күрсәткән. Бөтен җәмгыятьнең сәламәтлек дәрәҗәсе хатын- кызның тугрылыгы дәрәҗәсенә бәйле. Ислам хатын-кызны чит кешеләр каравыннан саклаучы бөркәнчек хәстәрен күргән. Бөркәнчек ир белән хатын арасында мәхәббәт һәм бер-берсенә бәйләнгәнлекне саклый. Хиҗаб кигән хатын-кыз беренче чиратта үзенең исән-иминлеген, ә икенче чиратта инде ир-ат саулыгын да кайгырта, чөнки бу өс киеме ирләр кызыга торган урыннарны яшерә. Шәригать хатын-кызларга чит ирләрне кызыктырмас өчен шулай итеп киенеп йөрергә боера. Мондый очракта, горур ир-ат та, хатынының матурлыгын беркем белән дә бүлешмәвенә сөенә.




Һәркөн иртә белән, өеннән чыкканчы, мөселман татар кызы көзгә янына килеп, үзенең кыяфәтенә күз сала. Ләкин киеме соңгы көн модасына туры киләме икән дип түгел, бәлки Аллаһы биргән зәвыклыгын чит күзләрдән яшерү нияте белән. Көннең эсселегенә карамый, ул озын күлмәген кия, башына яулыгын яба, чәчләрен җентекләп яшерә һәм урамга чыга... Ә бүген аны урамданиләр көтә? Кызганыч ки, бүген күп очракларда, башыңа яулык салып, үз хәләлеңә генә тугры булып яшәү, ким дигәндә, урта гасыр, искелек калдыгы булып тора. Шул бер яулык үзенә күпме карашларны тарта. Кемдер кызгана, кемдер шикләнә, кемдер соклана... «Әй, бичара, берәр сектага эләккәндер инде?»–диючеләре дә бар. Бигрәк тә Рәсәйнең зур шәһәрләрендә, кибеткә яулыклы кыз керсә, сакчылар аны, чыгып киткәнче, күзләрен дә алмый озатып калалар. Бүген бит терроризмга каршы көчле көрәш бара! Әмма мөселман хатын -кыз күңелен төшерми. Күңелендә булган бөек максат аңа яшәргә көч бирә, йөрәген тынычландыра. Ул максат–Бөек Раббысының ризалыгын казану. "Бу исә, тирә-юньнең аңлашылмаучанлыкларыннан, күрә алмаучанлыкларыннан күпкә өстендер... балкып торган мөслимә яулыгы: «Юк, Раббым, җәмгыять үлми, татар халкы яши, алга, сафлыкка бара!»–дип ялвара кебек.

Бүген, әйләнә тирәгә карасак, тулысынча дин кушканча бик аз хатын-кыз киенеп йөри. Кызганыч ки, бик күпләре яулыкны өстән генә эләләр дә, ачык муеннарын ялтыратып, джинсы, яисә башка тәнгә сылаша торган чалбар, кофта киеп урамга чыгып китәләр. Һәм ошбу рәвешчә киенгән хатын-кызлар үзләрен заманча киенгән мөслимәләр, калганнардан яхшы дип санайлар. Бу күренешне Төркия, Мисыр, Әзәрбайҗан, Мәгъриб илләрендә дә күзәтергә була. Бу хәл ислам дәүләтләрендә дә киң колач җәя бара. "Рәхмәт әле, яулык ябынып йөрегәнегезгә дә",- диясе килә килүен. Әмма ошбу күренештән Раббыбыз риза микән соң? Кайберләре аларга урамда ир-атлар игътибар итми дип уйлыйлар. Әмма, чынбарлыкта моның капма-каршысы исбатлана. Бу хакта сораштырган 10 мөселман егетенең тугызы "Игътибар итәбез",-дип җавап кайтарды. Моннан тыш, чын мөселман егетләре, шулай киенеп йөргән мөслимәләрне өнәп бетермәгәннәре хакында да әйттеләр. Аның өстәвенә мондый киенү рәвешенең бүтән яман йогынтылары да юк түгел. Бер күренекле Россия галиме, ирләрнең авыруларына хатын-кыз сәбәпче дип бара. Шуның аркасында импотенциягә һәм яман шеш авыруларына китереп җиткерүче «җенси яктан читкә кагылганлык»ның катлаулы эчке организм комплексы башлана. Бу хакта күренекле табиб, академик Л. А. Китаев-Смык үзенең «Стресс психологиясе. Стрессның психологик антропологиясе» («Психология стресса. Психологическая антропология стресса») дигән фундаменталь монографиясендә яза. Нәтиҗәдә, еш ярсынып та, канәгатьлек алмаган ир-ат үз организмында эчтән куәтле, җимергеч концероген һөҗүм ала һәм ул яман шеш авыруына китереп җиткерә.

Юныс Мөхәммәтша әйтүенчә: "Кайберәүләребез, бу татар кызлары нәрсәгә гарәп, төрек киемнәре киялəр соң дип, милләтебез өчен борчылабыз. Әмма, Ислам дине шәрыкчә дә, мәгрибчә да, гарәпчә дә, төрекчә дә, француз һәм инглизчә дә киенергә тыймый, мөселман күлмәгенең төп шарты–хатын-кызның зифа сынын яшерү, шуның белән җәмгыятьне азгынлыктан имин кылу".

Шунысы шатлыклы, җир йөзендә европалыларның урынын үз хатыннарының әхлакый сафлыгын һәм яшертенлеген саклый алган һәм шуның белән бергә шулай ук үз ир-атларын да саклый белүче халыклар алмаштыра. Беренче нәүбәттә, болар–ислам дөньясы халыклары. Гомумән, дини традицияләргә таянган барлык халыкларда да киемсалым культурасы шундый булган. Үз хатын-кызларының гыйффәтлеген, әхлакый йөзен саклап, җәмгыять бер үк вакытта үз ир-атларының да сәламәтлеген саклаган.

Күп кенә мөслимәләребез шәригать кушканча дөрес итеп киенеп йөри. Шундый мөслимәләребезгә карап горурлык хисләре кичермичә булмый. Алар–халкыбыз Аурупа йогынтысы астында үз әхлагын, телен һәм горефен югалтып барган бер заманда безнең, мең ике йөз ел яшәп, халкыбызны саклап килгән горефебезне саклаучылар. Башына ап-ак яулык япкан татар кызларыбыз, үз диннәре һәм милләтләре өчен горур басып йөри алалар. Асылыбызны саклап, сафлыкка чакыручы каһарманнар нәкъ шулар!

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**
**ӘЗЕРЛӘДЕ**

# Сорау илә җавап

**Хәзер яшьләр арасында интернет буенча никах турында күп бәхәсләр бара. Ул рөхсәт ителәме, юкмы? Рөхсәт ителсә, нинди очракларда аңа мөрәҗәгать кылырга була? Мөслимә**

Бу хакта уйлар төрле булырга мөмкин дигән фикерләр белән килешәм. Ник дигәндә, интернетка кагылышлы мәсьәләләрне Коръәндә дә, сөннәттә дә табып булмый. Ә менә никахның исламда җитди вакыйга икәнлегенә аятьләр һәм хәдисләр күп. Ислам күзлегеннән чыгып караганда, никах бөтен гомер буена укыла. Ул Аллаһ каршында зур җаваплылык, аның өчен кыямәт көнендә җавап бирәсе була. Бередә ата-аналарның фатихасын аласы бар, шаһитләрнең катнашуы мөһим, кияү кәләшкә кыйммәтле туй бүләге бирә, никах укыту турында халыкка җиткерелә һәм башкалар. Боларның барысы да кешеләрдә җаваплылык хисе уята.

Кеше үзенең табигате буенча йомшак. Бу хакта изге китапта да әйтелә. Ислам таләпләре һәм милли гореф-гадәтләр кешегә көчәергә булыша. Болар гаилә төзү мәсьәләсенә дә кагыла.

Интернет аша никахлашуны мин җиңел акыл белән эшләнгән гамәл дип саныйм. Алар хәзерге заманның яшерен һәм гражданлык никахы белән яшәүне хәтерләтә. Кайберәүләр сөяркәләре белән зина кылуны бу икенче, өченче, дүртенче хатыным дип аңлата. Бүгенге көндә җәмгыятьтә әдәп-әхлак популяр булмаганда, мин интернет аша никахлашуны зина кылуга якын, ягъни гөнаһлы гамәл дип атар идем.

**Миңа 25 яшь, өйләнмәгән, намазлар укыйм. Өйләнергә ниятлим. Күптән түгел бер татар кызы белән таныштым, әмма ул ислам дине йолаларын үтәми. Башына яулык бәйләми, намаз укырга теләми. Боларга аны өйрәтергә мөмкин дип уйлыйм. Аның якын араларда шулай ук кияүгә чыгарга исәбе бар. Мәхәббәт дигән нәрсә булмаса да, яшьнең һаман арта баруы киләчәк турында уйланырга мәҗбүр итә. Тик бер мөһим мәсьәлә бар: ул инде якынлык кылырга өлгергән, ә миндә андый хәлнең булганы юк. Хәзер инде нишләргә дә белгән юк. Миңа бу кызны ташлап, башканы эзләргәме, әллә шикләнүне бетереп, шуңа өйләнергәме? Руслан**

Шикләнүләрегез бөтен гомерегез буена сезне кимерәчәк дип уйлыйм. Моңа охшаш мисаллар язылган хатларның безгә килүе аңа дәлил булып тора. Сез мәчетләргә һәм дини чараларга йөреп тә үзегезгә туры килә торган кызны табарсыз дигән фикердә торам. Кияүгә чыгарга теләк белдергән кызлар күп бит. Аларны эзләргә вакытыгызны кызганмагыз.

**Минем белән берничә тапкыр шундый хәл булды: төнлә уянып киткәч, күзләремне ача, сулый алам, әмма хәрәкәтләнә алмыйм. Бармаклар катып калган, иреннәр дә селкенми. Бу вакытта кемдер мине күзәткән кебек сизәм. Мондый хәл бер минутка кадәр дәвам итә. Әлеге күренешкә берәр аңлатма бармы? Арсен**

Йокы ул–кече үлем, ял итү һәм безнең акылыбызга буйсынмаган көчләр белән элемтә каналы. Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) иртән йокыдан торгач, сәхабәләргә: «Чынлыкта, Раббыбыз Үзе теләгән вакытта сезнең җаннарыгызны алды һәм аларны теләгән вакытта кайтарып бирде»; «Рәхмәт безләрне үтергәннән соң яңадан терелткән Аллаһыга (Ул йокы вакытында җаннарыбызны алды һәм тормышны дәвам итү өчен аны кире кайтарды)»,– диде. Сезнең йоклаганда чыккан җаныгыз тәнегезгә акрынлап кире кайтканы өчен уянган чагында төш күргәндә шундый хәлләр килеп чыга.

**Җаваплар umma.ru дан алынды.**

---

**Шигъри дулкында**

## Урам буйлап

Урам буйлап әкрен
генә атлыйм,
Күзәтәмен гөлләр,
юлларны.
Урам як ул–хуҗасы
турында сөйли,
Шулчак күңел шигырь
көйли,
Язам әле менә шуларны.

Төне буе җырлый-җырлый,
Шайтан аракысын эчәләр.
Иртәгесен елга
ярына, урамга күчә,
Бушап калган
шыксыз шешәләр.

Инде аңга килергә
дә вакыт,
Тормыш юлы шактый
узылган.
Тик менә шул-юынтык
судан
Урам якка торба сузылган.

Ә монысы ярата әче-төче,
Аунап ята кетчуп каплары.
Суган, әфлисун
кабыклары.
Ташланган кап,
эчелгәнгә инде соклары.

Һич кенә дә
үзебез яратмыйбыз,
Иярeп керсә өйгә бары
бер яфрак.
Чисталыкны
бергәләшеп саклыйк,
Барыбыз да уяу
булыр чак!

Табигатьне
шакшылыкка күмеп,
Чисталыгын аның
урламыйк!
Калдыкларны теләсә
кая ташлап,
Үз-үзебезне
хурламыйк.

..................................

**ХАҖИЕВА ӘЛФИРӘ**

---


## Белдерүләр

*Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.

*Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)

*Мәдрәсә базасында таныштыру бүлеге эшли. Тел. 89625504168, 89372991485

*Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мәрәсимнәрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М.Җәлил ур 8/28), тел: 89172802391

*Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.

*Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь-мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.

*Мәдрәсә базасында Ислам диненә караган сорауларга җавап бирү хезмәте

**Белешмәләр өчен телефон: 89172802391**

*Мәдрәсә “Бер айда намаз укырга өйрән” түгәрәгенә укучылар җыя.

**Белешмәләр өчен телефон: 89372991485**


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**


**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**